# ГАДЕЛ КУТУЙ
1903-1945



# САГЫНУ

# Максат:

- укучыларның сәнгатьле уку һәм сөйләү күнекмәләрен, тыңлап аңлау сәләтләрен үстерү;

- яңа төшенчәләр белән таныштыру;

- балаларда туган якка мәһәббәт, горурлык хисе тәрбияләү.

# Өй эшен тикшерү.

- Кем ул Гадел Кутуй?

- Кайчан һәм кайда туган?

- Нәрсәләр язган?

# Нәрсә ул

- Чагыштыру?

- Әдәби кабатлау?

- Инверсия?

# Яңа материалны өйрәнү

- Әсәрдә сүз нәрсә турында бара ? Кем образы бирелгән?

- Әсәрнең укылышына, яңгырашына игътибар иттегезме? Ул үзенең укылышы белән нинди әсәргә охшаган?

- Нәсер турында ишеткәнегез бармы?

# Нәсер

«Нәсер» сүзе гарәпчәдән алынган һәм проза төшенчәсен аңлата. Нәсер ул хис-тойгы дөньясы. Нәсер жанры әдәбияттә сирәк очрый. Г.Кутуй нәсер остасы. Ул 1944 елда, фашистларга каршы сугышып йөргәндә, үзенең “Без – Сталинградчылар”, “Сагыну” нәсерләрен яза. Соңгысының эчтәлеге белән таныштыгыз да инде. Аннан сагыну хисе ташып тора. Чөнки аның исеме “Сагыну” бит.

- Сагыну нинди хис ул, укучылар? Нинди җирне без туган җиребез дип атыйбыз соң?

- Солдатның туган ягына, халкына булган мәхәббәтен, аларны юксынуын язучы нинди алымнар кулланып яза алды икән?

- Солдатның эчке доньясы ничек ачыла?

- Сагынуның ни кадәр көчле булуын белде-

рү өчен нинди җөмләләр кулланылган?

- Бу җөмләләр текстта ничә тапкыр кабат-

ланган? Аларны кабатлау нигә кирәк булды

икән?

- Нәрсә ул әдәби кабатлау?

Мәкальләр

Ватаны юк - җырсыз сандугач.

Илсез кеше - җырсыз сандугач.

Оясыз сандугач сайрамый.

Илең яхшылыкны онытмас.

Иле ныкның биле нык.

Илнең төтене дә тәмле.

# Туган як

- Туган як матур булганы өчен генә са-

гындырамы?

- Укучылар, Туган ил турында бик күп

шигырьләр, җырлар, мәкаль-әйтемнәр

дә бар бит.

# Йомгаклау

Сез бүген дәрестә нәрсәләр белдегез?

Дәрес сездә нинди тойгылар уятты?

Сезнең узегезнең сагыну хисе кичергәнегез бармы?

# Өйгә эш

Әсәрдән өзекне ятлап килергә.